Яңавыл районының 70 еллыгына

Сания ВӘЛИУЛЛИНА

# ЯЗМЫШ ҖИЛЛӘРЕ



Яңавыл,
2000 ел

Сания ВӘЛИУЛЛИНА

Кеше өчен эшләп шатланганда,
Үз бәхетем калды бер читтә.
Шушы гадәтемне ташламадым,
Саклый алдым әле ничек тә.

# Язмыш җилләре

## Чәчмә әсәрләр

## Шигырьләр



2000 ел

Язмыш җилләре (Судьбоносные ветры)
Яңавыл шәһәре, 2000 ел, 40 бит.
Вәлиуллина С., 2000 ел.



# Үзем хакында кыскача

Мин, Сания Фатих кызы Вәлиуллина, 1935 елның 25 гыйнварында Татарстанның Кукмара районы Сәрдәкбаш авылында тугханмын. Зур Сәрдәк урта мәктәбендә 9 сыйныфны тәмамлагач, гаиләбез Яңавыл шәһәренә күчте. Аттестатны Яңавылның 1 санлы урта мәктәбендә алдым. Бөре педагогия институтының физика-математика факультетын тәмамлап, Яңавылга кайттым. 1 һәм 3 санлы урта мәктәпләрдә математика укыттым.

Башкортстанның мәгариф отличнигы. Әдәбиятны яратам. Мәктәп елларында стена газетасы һәм мәктәп радиосында шигырьләрем файдаланыла иде. Балалар өчен язарга яратам. Шигырьләрем Яңавыл, Кукмара (Татарстан) район газеталарында һәм «Сөембикә» журналында басылды. Соңгы елларда «Өмет» газетасының «Чаткылар» кушымтасы битләрендә һәм Казандагы «Татар теле» газеталарында дөнья күрә.

Мин — ике бала анасы. Кызым Рина — Әлмәт муниципаль университетында укытучы, улым Ильмир — Әлмәт бораулау идарәсендә өлкән геолог булып эшли. Ике оныгым — Дилшат һәм Алмаз — үсә. Балаларым һәм оныкларым белән аралашып һәм аларга куанып яшим.

# ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

## Язмыш җилләре

Тиф авыруы кешеләрне аяусыз кырды. Балтач районы Борбаш авылы урманчысы Мостафа Мөхтәров гаиләсен дә урап узмады ул. Башта үз гаиләсе белән яшәгән кызы Зөлкамалны һәм Казанда хәрби уку йортын тәмамларга торган улы Мортазаны җирләде. Ике атна үткәч, җиткән кызы Шәмсинур белән улы Сираҗетдин вафат булды. Авылда укый-яза белүе белән дан тоткан, урта хәлле Мостафа агай зур кайгыга калды. Балалардан соң бер атна үткәч, хатыны Бибикамалны җир куенына тапшырды. Имчәк баласы гына булган, бер яшьтән яңа узган кызы Каймә ятим калды. Мостафаның янып торган күзләре тоныкланды, кап-кара чәчләренә чал кунды, зифа буйлары һәм тулы гәүдәләре хәлсезләнде. Ярый әле олы кызы Өммекамал, уртанчы кызы Тайбәанын һәм имчәк баласы Каймәнең соңгы өметләре булып калдылар. Әтиләре дә хәлсезләнеп түшәккә егылды. Күп тә үтми, ул да дөньядан китте. Өч кыз бөтенләй ятим калды. Ярый әле авыл халкы, күршеләре бар. Алар һәрвакыт ярдәм итеп тордылар. Салкыннар килеп җитте, әти-әниләреннән калган ризыклар да бетте. Сыерны һәм сарыкларны да саткач, көянтә ясау белән дан тоткан күршеләре Шәпи агай өлкәнрәкләргә кече сеңлеләре Каймәне балалыкка бирер өчен күрше авылларга йөреп чыгарга киңәш бирде. Ике апа, сеңелләрен чанага төреп утыртып, Салавычка юнәлделәр. Анда юллары уңмагач, ераграк авылларда да йөреп карадылар, әмма кыз баланы алырга теләүче кеше табылмады. «Малай булса, алырлар иде, кыз баланы алмаслар шул», — диделәр күршеләре. Мостафаның ике туган энесе Мәхмүт, үз өен калдырып, кызларга ярдәм итәр өчен күчеп килде. Тормыш аз булса да җиңеләйде. Каймә өч яшькә җитте. Мәхмүт агай Сәрдегән авылыннан Мөхлисә исемле кызга өйләнде. Тик, үзләренең балалары тугач, тормыш үзгәрде. Кызларга яшәү авырайды. Дүрт яшьлек Каймәне яңадан балалыкка бирергә карар иттеләр. Кызлар ерак авылларга йөреп чык-

тылар. Ниһаять, бу хәбәрне ишетеп, Сәрдекбаш авылыннан Фәхретдин исемле кеше килде. Матур җәй уртасында, ябык гәүдәле, ак йөзле, бөтенләй чәчсез калган дүрт яшьлек Каймә туган өен, туган якларын ташлап, ат арбасына утырып, балалыкка — бәхет эзләп юл тотты.

Еллар үтте, Сәрдекбаш авылы аның туган авылына әверелде. Фәхретдин агайның җиде ел балага узмаган килене, бу гаиләгә Каймә килгәч, сабыйларны дөньяга бер-бер артлы тупылдатып кына торды.

Каймә Мәгъмүрә апасының Галләметдин, Мифтахетдин, Канәфетдин, Бәдегетдин һәм Гыймазетдин исемле улларын тәрбияләп үстерергә ярдәм итте. Бәхет алып килде ул бу йортка, үзе дә бәхетсез булмады. Матур кыз булып үсеп җитте.

Тормышлар үзгәрде, колхоз төзелде, аңа «Мәдәният» исеме бирделәр. Беренче колхоз рәисе Әхмәдулла абзый колхоз бозауларын карауны Каймәгә ышанып тапшырды. Ликбез ачылгач, Каймә, кичләрен яшьләр белән укырга йөреп, укырга-язарга өйрәнде. Гаиләдә малайларның яраткан апасына, олыларның сөйкемле, чибәр, эшчән кызына әверелде Каймә.

1934 елда Сәрдекбаш авылында чыпта сугу артеле ачылды. Аның рәисе итеп Чишмәбаш авылы егете Вәлиуллин Фәтхерахманны куйдылар. Чишмә юлында, суга барган Каймәне очратып, аңа күзе төшеп калды егетнең. Ул аны беркемгә дә бирмәскә ант итте. Шул айны өйләнде. Фәхретдин агай, Каймәне үз кызы кебек якын күреп, никах укытты һәм туй үткәрде. Авылда ике катлы йортта яши бирделәр. Егет бик үткен булып чыкты. Донбасс ягына китеп, шахтада эшләде, сугыш елларында Кизель шахтасында күмер чапты, сугыштан соң Зур Сәрдек авылында сельпо рәисе итеп, Чишмәбашта колхоз рәисе итеп тәгаенләнде, хәтта Норвегиянең Шпицберген утравында да булып кайтты ул. Ә Каймә җиде бала белән аны көтте.

Өч кызы һәм дүрт улы үсте аларның. Сания — математика, физика укытучысы, Башкортстанның мәгариф отличнигы. Саймә — тимер юл эшчесе, илебезнең күп шәһәрләрен гизгән эшче. Баязит — гармунчы,

оста җырчы. Басыйр, Казан медицина институтын тәмамлап, Нефтеюганскида уролог-хирург булып эшли. Әлфия — бухгалтер. Рифкать Казан финанс-икътисад институтын тәмамлады, Нефтеюганскида нефтьче. Вәсил — тепловоз йөртүче...

Җиденче бала булып туган, асрама кыз булып үскән Каймә — җиде бала әнисе, иң бәхетле ана булып яшәде. Аның туган көне, туган елы билгесез булса да, әтисе 1911 елда, 7 ноябрь көнне туган, дип яздырган. Бу көн һәр ел саен безгә зур бәйрәм. Сөйкемлелек, тыйнаклык, сабырлык, пөхтәлек сыйфатларын аңа Балтач, Кырлай яклары биргәндер, мөгаен. Менә берничә ел инде ул безнең арабызда юк. Матур тормышта яшәде ул. Балалары белән горурланды. Үзе ятим үссә дә, безнең белән тормышы тулы булды. Аны бәхетле ана дип йөрттеләр. Ул, чынлап та, бәхетле иде. Язмышы үкенечле булмады, киресенчә, ул тормышыннан бик тә риза, язмышыннан канәгать иде. Бер баласы да аның йөзенә кызыллык һәм тап төшермәде, 12 оныгы да аны яратып дәү әни дип йөрттеләр. Оста җырчы, такмакчы, шигырь сөюче һәм әкиятче, яраткан әниебез һәм дәү әниебез иде ул. Аның язмышы безгә горурлык.

# Күңел күзең күрмәсә

### Хикәя

Урып-җыю эшләре тәмамланып килгән чак иде. Үзе эшләгән автотранспорт предприятиесеннән Радикны машинасы белән ерак колхозга командировкага җибәрделәр. Егет моңардан бик канәгать иде. Яңавыл элеваторына ашлык ташый, хәтта өенә дә кереп тормый, чөнки кабинада яшь кызлар була. Менә бүген дә ул, ашлыгын бушатты да, шәһәрдән алып чыга торган урамга борылды. Шунда үзеннән шактый алда, юл

читеннән атлап барган бер кызга күзе төште. Кабинада кызлар булганда юл кыска тоела, йокы кача, алар белән сөйләшеп баруы үзе ни тора. Үзе шофер, үзе гармунчы егетне кем яратмасын. Кичләрен клубка чыгып, гармунда уйнап, аларны биетсә, хатыны һәм улы барлыгы бөтенләй онытыла. Кызлар күргәч, селәгәе ага егетнең. Менә бүген дә ерактан күзәтеп килгән кызның янына якынлашкач, машинасының тизлеген киметте дә, шып итеп килеп туктады. «Яңавылда бу чибәркәйне күргәнем юк, я кунакка килгән, я эшкә җибәргәннәрдер, мөгаен», — дип уйлады Радик.

— Әй, чибәркәй, әйдәгез, утырыгыз, аякларыгыз ял итсен, — дип кабинасын ачты.

Кыз өстенә ап-ак плащ, аякларына матур кыска итекләр кигән, кулына ак сумка тоткан. Куе кара чәчләренә биек прическа ясап, башына һава кебек зәп-зәңгәр ефәк шарф бәйләгән.

Кыз юл читеннән атлавын белде. Радик акрын гына машинада аның артыннан баруын дәвам итте. «Ә фигурасы нинди матур», — дип уйлап куйды эченнән генә.

— Әйдәгез, ялындырмагыз, кызыкай, күтәреп утыртканны көтәсезме әллә? Мин хәзер... — дип, машинасыннан төшеп, аның юлына аркылы басты да, аптырап калды. Каршында Гөлфия елмаеп басып тора иде.

— Әй, шайтан, син исәнмени? Өйгә кереп чыгарга вакыт таба алмыйсыңмы әллә? Улың Айрат сине көтә бит! Нәрсә аптырап калдың? Әйдә, мине эшкә илтеп куй, — дип кабинага кереп утырды.

Агарып каткан, аяклары дерелдәп калтыранган Радик, әкрен генә машинасына таба атлап: «Күңел күзең күрмәсә, маңгай күзе — ботак тишеге дигәннәре шул буладыр инде ул», — дип, кабинасының ишегенә таянып, аңына килү өчен бераз йөрәге сикерүе басылуын көтеп торды.

# «Печать» Рәвил

## (Булган хәл)

Сабантуйга кызып әзерләнгән мәлдә генә Ярулла Нәбиевич колхоз мөһерен (печатен) югалтты. Хатыны Миңнебану да зур кайгыга калды. Бухгалтер Хатип агай да бу хәлгә аптырады. Мөһер эзсез югалды. «Районга барып хәбәр итми булмас, партия билетым белән хушлашырга туры килсә килер», — дип өенә атлады.

Өйләре янында бер төркем балалар уйнап йөри иде. Капкадан керүенә Зиннәтулла малае Рәхимулла, йөгереп килгән уңайдан, аңа килеп бәрелде. Аннан:

— Исәнмесез, Ярулла абый? — дип башын күтәрде.

Колхоз рәисе сүз әйтергә дә өлгермәде, малайның маңгаендагы мөһер эзләрен күреп, телсез калды. Йөгереп китеп баручы Рәхимулла артыннан кычкырды:

— Рәхимулла әнем, кил әле минем яныма.

Малай тиз генә кире килеп итте.

— Бу өч пичәтне маңгаеңа кем сукты?

— Улыгыз Рәвил сукты. Безнең урам малайларының тамгасы шул. Без Сабантуйга шулай чыгабыз да, аргы як малайларын көрәштә җиңәбез.

Ярулла Нәби улы мөһернең эзенә төшүенә сөенеп, көлеп җибәрде. Ә малайга бу көлү бик ошады булса кирәк, дәртләнеп йөгереп китте.

Өенә керүенә, улы Рәвил өстәл артында ашап утыра иде.

— Улым, барлык малайларга да пичәт сугып бетердеңме?

— Әйе, әти, кызларга сукмадык.

— Ә хәзер миңа бир инде.

— Ул эшләми башлады бит, әти.

— Мин аны үзем эшләтәм.

Алар бакчага чыгып, кара янчык эчендәге колхоз мөһерен каен агачы төбеннән казып алдылар.

...Бу вакыйгага күп еллар үтте. Ярулла Нәби улы Бөек Ватан сугышына китеп хәбәрсез югалды. Ә улы Рәвил үзе бабай хәзер. Әтисенең истәлеге итепме, «Печать» Рәвил дип атыйлар. Ә балаларын һәм оныкларын «Печатьнекеләр» дип йөртәләр.

# ШИГЫРЬЛӘР

## Әбиемнең йөрәк хатлары

*Җиңүнең 55 еллыгына*

Кызыл флаг тотып, укучылар
Җырлап үтте урам буйлатып.
Канлы сугыш бетте, зур тантана бүген,
Күрче, халкым, илдә зур шатлык.
Әбиемнең күз алдында
Бер-бер артлы киткән уллары.
Дүртесе дә кайтыр,
Ул аларны көтә...
Ник еракта бүген уйлары?
Әйе, уйга калып, карап тора
Киткән юлларының чатына.
Артта калыр, әби, кайгыларың,
Шатлыкларың килер алдыңа.
Барыгызны җыеп, гөрләшүләр —
Булыр микән миңа шул чаклар?
Барып җитсен сезгә сәлам булып
Күңелемнән язган бу хатлар.



## *Беренче хат*

Әһелулла улым - иң олысы минем,
Председатель иде авылда.
Фашист илгә кергәч, теләп китте,
Нәфрәт белән дошман явына.
— Җибәрегез мине фронтка, — дип,

Кукмарага бардың һәр иртән.
— Тап төшермәм Гаффар нәселеңә — дидең, —
Мин олысы, әни,
Башлап мин китәм.
Киттең. Җиде бала белән
Миңнебикәң калды.
Балаларың үсә, исәннәр.
Кичә җыелышта
Кызың Разияны
Бригадир дип
Сайлап үткәннәр.
Ирләр юк шул, яшьләр дөнья көтә,
Сайлап куеп, дөрес иткәннәр.
Икенчесе — Мәрзияң дә үсеп җитте,
Җырларында моңы, сагышы.
Чишмәбашның җырчы кызы, диләр,
Тыңлап туймыйм — моңлы тавышы.
Бердәнберең — улың Мансур үсә,
Һәр көн килә минем өемә.
Нәрсәм булса, шуның белән сыйлыйм,
Тамак туйса, сабый сөенә.
И өзелә үзәк, и сызлана йөрәк,
Мөхлисулла үткән чакларда,
Хат та кертми,
Бик сагындым, улым,
Тиз кайтыгыз туган якларга.
Иртән торсам, көн дә хәбәр көтәм,
Күзем, улым, һәрчак ишектә.
Исән генә йөреп, сау кайтыгыз,
Мин түзәрмен әле ничек тә...

## *Икенче хат*

Ә Ярулла — минем икенчесе.
Колхоз җитәкләде Тырышта.
Яшьләр белән колхоз оештырды,
Нигез салды яңа тормышка.
Кукмарадан кайтып үтешли,
Чишмәбашка керми китмәдең:
— Әни, хәлең ничек? Чәең бармы?
Юкмы пешкән җылы икмәгең?
«Эшебез күп, ара — ерак», — дими,
Бик еш кына миңа килдегез.
Улың Равил бездә туган иде,
Исемен дә бездә бирдегез.
Исеңдәме?
Энең Фәтхерахман белән
Бер үк айда туды кызыгыз.
Шунысы кызык,
Икегез дә, белми
Сания дип исем куштыгыз.
Еллар авыр тора, ачлык хөкем сөрә,
Тән өшетә ачы җилләре.
Кызың Суфия да гүр иясе булды,
Йомшак булсын яткан җирләре.
Калганнары әйбәт кенә яши.
Килмәделәр әле бу тирә.
Балаларны ач-ялангач итми,
Миңнебану килен үстерә.
Уйга чумып, карап торам
Сезне озаткан юлның чатында.
Шатлык көтәм.

Никтер, кайгы килер,
Саклап тора кебек артымда.
Урамнарга чыгам,
Почтальонны көтөм,
Күзем, улым, һәрчак ишектә.
Исән генә йөреп, сау кайтыгыз,
Мин түзәрмен әле ничек тә...

## *Өченче хат*

Абыйлары киткәч, күңелемне
Саматыма карап юаттым.
Бер айдан соң аңа хәбәр килде —
Өченчесен тагын озаттым.
Хәбәр алганчыга кадәр
Атна элек:
— Әни, — диде, — алам мин кәләш!
— Дөрес уйлагансың, улым,
Бик тату без,
Шәмсебану килен — зур иптәш.
Төн — караңгы,
Кичен чәй эчәбез.
Тынычлыгын бозып бүлмәнең,
Габдулла улың елый.
Ул сабыйның
Нурлы йөзен әле күрмәдең.
Туганын да хәтта белмәдең.
Күз яшьләре аша, Самат улым,
Аңа озын гомер теләдем.
— Елавыма, килен,
Гаҗәпләнмә, — дидем, —
Аптырашта калма тагы да.

Самат исән, аны улы көтә,
Кайтып керер әле табынга.
Яше, карты, бар да эшкә йөри,
«Фронт өчен эшлик», диелә.
Атлар җитми, һәрбер хуҗалыкның
Сыерлары эшкә җигелә.
Беркөн сыер
Гаҗәп хәлгә куйды,
Килә алмый торам аңыма.
Бозавы яшь.
Эштән качып кайтты
Тырма сөйрәп ишек алдына.
Басуда да эшли, бозау үстерә,
Сабыйларга сөтен өләшә...
Кеше генә түгел,
Явыз фашист белән
Сыерлар да, улым, көрәшә.
Семьябыз зур, унбер кеше яши,
Сыер безнең терәк тормышта.
Ат һәм сыер кеше белән бергә
Өлеш кертә барган сугышка.
Бездә генә күпме сабый үсә —
Авыр елда туган балалар.
Әнисенең күкрәк сөтеннән үк
Сугыш зарын татып баралар.
Берсе әле буйга үсеп килә,
Тәпи атлап китә кечесе.
Күкрәк сөте белән үстерәләр
Алгы көннең иң зур кешесен.
Биләүләрдән чишеп җибәрүгә,
Күкрәкләргә үрелә балагыз.
Киленнәрем, күкрәк сөтегезне

Яшәү көче итеп санагыз.
Моңа кадәр түздек,
Җиңү көне җитәр,
Түзем булуларга ни җитә?
Исән йөреп,
Сау кайтыгыз, улым,
Без түзәрбез әле ничек тә...

## *Дүртенче хат*

Уйга чумып, тагын басып торам
Якуп тыкырыгы чатында.
Хатлар көтәм.
Ләкин хәбәр алдым
Сәгыйдуллам китү хакында.
Унсигез яше генә тулган иде
Сәгыйдуллам киткән чагында.
Ике айдан дүртенчесе китте,
Ярый әле калдым аңымда.
Хатларында яза:
— Кайтырмын, — дип, —
Әни бәгърем, бераз түз инде.
Ат өстендә фашист куам, — дигән.
Зәйтүнәгә язган:
— Көт мине.
Сталинградтан язган хатың тора,
Ә нигә соң тагын язмадың?
Төшләремдә кара атта күрәм,
Тик әйтмисең кая барганың?
Бакчаларда йөрим,
Бик еш кына

Үзем белән үзем сөйләшәм.
Күңелемнән сезгә хатлар язам,
Дүрт кисәккә бүләм, өләшәм.
Җиде балам ятим калып үсте,
Сез үстегез, гүя, һәр сәгать.
— Баһадирлар үсә, Өммегөлсем! —
Дия иде күрше Фәсахәт.
Капка төптә почтальонны көтәм,
Күзем, өйдә чакта, ишектә.
Исән генә йөреп, улым, сау кайтыгыз,
Без түзәрбез әле ничек тә...

* * * * * *

Менә җәйләр үтте.
Көзге яңгыр ява,
Саргайдылар агач, үләннәр.
Исән солдат инде күптән кайтты,
Ай, кайтмый шул инде үлгәннәр.
Мин аларны сыңар канат белән,
Яшәр өчен диеп, үстердем.
Күз яшьләрем акты елга булып,
Хәзер акмый, коеп бетердем.
Челпәрәмә килде бар өметем,
Канаты юк өмет кошымның.
Сүнде кебек миңа бар яктылык,
Чаткысы юк янган утымның.
Яраларым тирән, ай, сызланам,
Даруларны каян табасы?
Ачыдан да ачы (түземлегем бетте)
Дүрт хәбәрсез улым ярасы.
Сулар акты, еллар үтә бирде,
Ил төзәтте инде ярасын.

Без, аналар, тик аналар гына
Таба алмас газиз баласын.
Төнлә уйлап, таңда хатлар язам,
Каршы алам көн дә ал таңны.
Дүрт улым, сез яуладыгыз аны,
Оныгмас, дим, сезне Ватаным.

* * * * * *

Әби көтте.
Айлар, еллар үтте,
Телгәләнде аның йөрәге.
Дүртесенең барсын,
Барсын бергә
Күрү иде
Аның теләге...
Күзләре дә
Төпкә утырдылар,
Чәчләре дә күптән агарган.
...Әбиемне сугыш кайгылары
Алып китте
Безнең арадан.
Алда кабер.
Үсә яшел шомырт,
Ап-ак чәчәк ата язларын.
«Лепер-лепер» итеп
Яфраклары сөйли
Әбиемнең йөрәк хатларын.

## Туган як

Сагынам, туган як,
Еш искә төшәсең.
Бала һәм үсмер чак,
Төшемә керәсең.
Имәннәр, каеннар
Ак шәлен ябынгач,
Кайтырмын, авылым,
Өзелеп сагынгач.
Мәшәкатьләр тотты,
Ашмады теләгем,
Талпынып, ашкынып
Ярсыды йөрәгем.

Күз алдымнан китми
Авылымның яме.
Әле дә телемдә
Суларының тәме.
Очыртам сәламем
Язгы садә җилләргә.
Җилкәем, алып кайт
Мин туган җирләргә.
Сәламем кабул ит,
Садә җилләр илтсәләр.
Ышанма, авылым,
Оныткан, дисәләр.

## Урал тау бөркете

### (Мостай Кәримнең юбилее уңаеннан)

Урал тауда горур бөркет оча,
Тирәсендә нәни бөркетләр.
Кар өстенә канатыннан тама,
Җемелдәшеп, энҗе бөртекләр.
Көчсез, хәлсез кошлар язмышларын
Үз язмышы белән тиң итте.
Биекләрдән биекләргә очты
Урал тауның
Олы бөркете.
Кыяларга менеп, киң галәмдә очты.
Хөрмәтләде Урал бөркетен.
Яңа гасыр таләпләре бик зур...
Чынга ашсын,
Бөркет, өметең!

## Октябрь бүләк иткән

Безнең әнине, чыннан да,
Октябрь бүләк иткән.
Нәкъ шушы бәйрәм көнендә
Ул безнең туган икән.
Ятим калса да, яшәгән,
Октябрь булган ана.
Яшәткән, үстергән аны,
Ул булган аңа ата.
Гөл-чәчәкләр таҗын ача
Җылысыннан кояшның.
Ул да тойган Октябрьның
Җылысын һәм юлдашын.
Җиде туган телибез без
Озын гомер, тынычлык.
Димәк, без дә Октябрьга
Язмыш белән бурычлы.

## Килмә, картлык

Картлык ишегемне кага,
Куркыта йөрәгемне.
Ярсып, ашкынып килә ул,
Сорамый теләгемне.
Сырлар, йөзне капламагыз,
Күз, син күр дөнья йөзен.
Аяк, куллар сызламагыз,
Яшәргә телим үзем.
Исәпләсәм, хәйран калам
Үткән юл чакырымын.
Картлык, әгәр кирәк булсаң,
Мин үзем чакырырмын.

Һәркөн ишегемне какма,
Куркытма, син, вакытсыз.
Нигә шулай ашыгасың,
Яшим әле картлыксыз.
Әйләнә-тирәмдә йөрмә,
Саклама мине шулай.
Яшәргә телим әле мин,
Гомерне бирсә Ходай.

## Кызлар

Җиткән кызлар... Алсу җиләк кебек...
Сокланасың карап йөзенә.
Ә кичләрен, тулы Айга карап,
Бәхет тели алар үзенә.
Ай нур сибә, Ай дәрт өсти,
Кавыштыра Айның яктысы.
Ә кызларга олы бәхет өстәп,
Йөзләрендә балкый яктысы.
Җиткән кызлар сөйгәннәрен көтә,
Сер сөйлиләр берсе-берсенә.
Ә кичләрен, тулы Айга карап,
Бәхет тели алар үзенә.

## Чишмәбашым

**Җыр**

Синдә туды яшьлегемнең
Кайнар сөю хисләре.
Кыш та, яз да, җәй дә матур
Чишмәбашым кичләре.

*Кушымта:*

Челтер-челтер чишмә ага,
Үбеп ак чуер ташын.
Авылымны бик сагындым,
Көтәдер Чишмәбашым.
Чишмә суларын эчәргә
Кайтам мин, Чишмәбашым.

Зур көч бирә чишмә суың
Сусаган вакытларда.
Иң сылу кызлар, егетләр
Тик безнең авылларда.

*Кушымта.*

Балта осталары бит ул
Чишмәбаш егетләре.
Дан казана мамык шәле
Һәм киез итекләре.

*Кушымта.*

## Аккошлар

Күл өсләрен бизәп, Аккош йөзә,
Сокландыра һәрбер парыгыз.
Безнең якның гүзәллеге булып,
Җәй җәйләргә бездә калыгыз.
Аккошлардан сылу кошлар бармы?
Алар мәхәббәтен кем тойган?
Ала алмыйм күзне Аккошлардан,
Китә алмыйм күлнең буеннан.
Аккошкайлар! Сезне яратабыз,
Тыныч кына оча бирегез.
Һәр ел саен бала үстерергә
Туган якка — безгә килегез.

## Яңавыл

### Җыр

Яңавыл, туган ягым —
Киң дә, иркен дә, бай да.
Андый матур шәһәрне
Күргәнем юк беркайда.

*Кушымта:*
Ямьле Бүә буйларында
Иртә-кичен күк томан.
Яңавылның һәрбер киче
Мәхәббәт белән тулган.

Бездә яши уңган халык —
Укый, эшли, ял итә.
Тимер юллары, теләсәң,
Еракка алып китә.
*Кушымта.*

Яңавыл — яңа шәһәр,
Утларың синең зәңгәр.
Килгән кеше кире китми,
Килсәләр сиңа әгәр.
*Кушымта.*

## Оныт, диләр

Оныт, диләр, миңа
Ана телен.
Әти, әни, нәсел телемне.
Юк, онытмам,
Алай була калса,
Мин югалтыр идем илемне.
Горурланам татар
Булуыма,
Милләтем бит
«Татар» язылган.
Сабый чакта
Саф татарча
«Әннә» диеп телем ачылган.

## Яңа ел, хуш киләсең!

Яңа елның яңа көнен
Каршылыйбыз бергәләп.
Сау бул инде, үткән гомер,
Китмә безгә үпкәләп.
Яңа елның яңа кары
Яусын урман, кырларга.
Мул уңышлар шаулап үссен
Кар яткан басуларда.
Яңа елның яңа көне,
Түргә уз, хуш киләсең!
Төкле аяк белән атла,
Яңа гасыр иртәсе.

## Яз килә

Яз килә җиргә,
Суларга җиңел.
Яшәрә җирләр,
Талпына күңел.
Кар эреп бетеп,
Су булып агар.
Елга ярларын
Дулкыннар кагар.
Кырлар чакыра
Трактор дустын.

Сөр һәм чәч, дияр,
Ашлыклар уңсын.
Яшәрә урман,
Болын, тугайлар.
Сыерчык килде,
Килер тургайлар.
Шатлана илем,
Яшәрә кырлар.
Шауласын тормыш,
Яңгырасын җырлар.

## Матур Бүә буйлары

Бүә буе яшел болын —
Килә күз алларыма.
Барган саен сокланам мин



Шул Буә талларына.
Камышлы күле бик матур,
Кыр үрдәкләре йөзә.
Агачта кошлары, сайрап,
Үзәкләремне өзә.
Кычкыра кәккүк ерак,
Яшә, дип, озак-озак.

## Күңелләрне бәйләп күңелгә

Төрле җирдә
Туып үссәк тә без,
Йөрсәк тә без төрле сукмактан,
Язмышыбыз бердәй,
Эшләр уртак —
Мәктәпләргә барып тоташкан.
Көч өстенә
Белем өсти-өсти,
Тәҗрибәләр туплап гомергә,
Эшләдек без,
Җигүле ат булып,
Күңелләрне бәйләп күңелгә.

## Ничек хәлегез?

Туган якны өзелеп сагынганда,
Кайтып киләм туган авылга.
Яшьлек сукмагыннан кабат үтәм,
Һич карамый җилгә, давылга.
Йөргән юллар, таныш урамнарым,
Авылдашлар, ничек хәлегез?
Болыннарда уйнап, суда йөзеп,
Синдә үскән кызлар идек без.
Челтерәп аккан елга, тау чишмәсе,
Суларыгыз әле тәмлеме?
Җәйге кичтә җырлап үткән уенлыклар
Без бардагы кебек ямьлеме?
Түбән очта яңа урам күрәм, —

Авыл үсә икән тагын да.
Яшьләр хәзер ташлап китми,
Язмыш үзе бәйли авылга.
Кайттым, күрдем,
Бик сөендем.

## Оныгым

### Җыр

Көйдерә дә, сөйдерә дә,
Оныгым яраттыра.
Көн саен үсә барып,
Үзенә караттыра.
*Кушымта:*
Тиз-тиз генә үс инде,
Егет булып җит инде.

Ерак китсә, сагындыра,
Өзелә бәгырьләрем.
Үзем әби булгач тойдым
Оныклар кадерләрен.
*Кушымта.*

## Син утырткан миләш

### (Әнем Баязит истәлегенә)

«Гомереңне озынайтыйм дисәң,
Агач утырт», — дигән олылар.
Киләчәктә, әнем, миләшләрең
Бакчабызны бизәп торырлар.
Тиздән алар күтәрелер күккә,
Үзең кебек, зифа, бик матур.
Ул сәламләп каршы алыр безне
Һәм, сәламләп, юлга озатыр.
Истәлеккә, диеп, утырткансың икән
Миләшеңне безгә, туганым.
Без аңладык инде, мәңгелеккә
Синең төсең булып калганын.
Кое янын бизәп миләш үсә,
Җимешләрен бирер бер заман.

Явызларның кулын тидермичә,
Үстерербез, диеп ышанам.
Язлар саен чәчәк атар миләш,
Кошлар килеп оя корырлар.
...«Гомереңне озынайтыйм дисәң,
Агач утырт», — дигән олылар.

## Онытмадым сине

Туган ягым,
Сокланырлык ямең,
Күңелемне тарта үзенә.
Озак еллар
Кайтмый яшәсәм дә,
Онытмадым сине һич кенә.
Туган авылым,
Саф һавалы авылым,
Суың синең
Тәнгә шифалы.
Мин мәңгегә
Синең кызың, авылым,
Җылы, рәхәт, иркен кочагың.

## Гөлем

Язын матур үсеп килгән гөлем,
Җәй уртасы җиткәч, ник шиңгән?
Таптаганнар үзен, нинди хәлсезләнгән,
Матуркаем, сиңа кем тигән?
Гөл бакчасын бизәп утырган гөл,
Башың имә, сиңа су сибәм.
Җәй атмаса, чәчкәң көзен атар өчен
Явызларның кулын тидермәм.



## Язлар яшьлек хәтерләтә

Яз кояшы,
Сине көтәм,
Нурыңны сип күберәк.
Елмаеп,
Көлеп кенә тор,
Җир җылынсын тизерәк.
Карлар эреп,
Сулар аккач,
Күтәрелер күк томан.
Ә табигать
Үз җылысын
Миңа да бирер сыман.
Язлар яшьлек хәтерләтә,
Бик мохтаҗ мин назына.
Юлын тапсам, барыр идем
Мәхәббәтем янына.

## Яшел каен

Язлар белән сиңа киләм,
Белим, диеп, хәлеңне.
Каенкаем, бәркән инде
Яшел ефәк шәлеңне.
Иңеңдәге яшел шәлең
Бик килешә үзеңә.
Ай, сылу син, каенкаем,
Күз тимәсен үзеңә.
Һәрвакыт тор
Горур гына,
Шәлең салып муеныңа.
Кочып алып, назла мине,
Яшер яшел куеныңа.

## Чишмә

Авыл таңын сәламләгән чишмә
Агып килә таудан, ерактан.
Көмештәй саф энҗе тамчылары
Тулып ага ике улактан.
Кош кулларга алып, су эчкәннәр,
Рәхәтләнеп, тыңлап тавышын.
Ярларына утырып тыңлаганнар
Көмеш суларының агышын.
Чишмә сукмагында, минем әти,

Әниемне күреп, танышкан.
Чишмә суы саф мәхәббәт биргән,
Яшь йөрәкләр сөеп, кавышкан.
Чишмә аккан,
Еллар исәпләми,
Һаман ага
Ярсып, уралып.
Сукмагыннан яшьләр атлаганнар,
Саф суыннан яңа көч алып.
Бир син, чишмә,
Минем әниемә
Шушы суның тик бер тамчысын.
Алып кайтыйм әле күчтәнәчкә
Яшьлегенең
Тәүге чаткысын.

## Розалия

Бакчабызда чәчәк ата
Роза белән лилия.
Бик сокланып карамагыз,
Гөлләремә күз тия.

*Кушымта:*

Розалия, Розалия,
Яратамын үзеңне.
Роза гөленә ошатам
Синең нурлы йөзеңне.



Гөл бакчасына керәсең,
Гөлләргә су сибәсең.
Гөлкәйләрем чәчәк атсын,
Беркайчан да шиңмәсен.

*Кушымта.*

## Дан сезгә, апалар

**Шәфкать туташларына багышлана**

Зәп-зәңгәр күзләре,
Ягымлы йөзләре,
Күпләрнең күңелен
Күтәрде сүзләре.
Кечкенә куллары
Фронтта күпләрнең
Бәйләгән ярасын
Һәм тапкан дәвасын.
Көн сугыш, төн сугыш —
Ял көне булмаган.
Киң сугыш кырлары
Зур ярдәм сораган.
Сырланган йөзләре
Күп сагыш сөйлиләр.
Фронтовик күкрәген
Медальләр бизиләр.
Ул сугыш еллары
Төш булып калалар.
Данлы юл үттегез,
Дан сезгә, апалар.

## Мәктәбем-горурлыгым

Гади генә мәктәп.
Шау-гөр килеп,
Уртасында яши урамның.
Без беләбез, аның Яңавылда
Иң беренче мәктәп булганын.
Без беләбез аның киләчәген,

Без беләбез аның үткәнен.
Без беләбез аның туган илгә
Күпме белгеч бүләк иткәнен.
Ә шулардан берсе —
Радик Гәрәевның
Бездә укып, җырлап үскәнен.
Безнең мәктәп —
Яшьләр исәбендә,
Маяк, диләр, аның турында.
Белем чыганагы,
Стадион да...
Клуб була
Кирәк чагында.
Остазлары хезмәт сөйгән өчен
Укучылар эшләп яшиләр.
Тырыш хезмәт юлын күрсәтүдә
Үрнәк бездә эти-әниләр.
Мәктәп яши шаулы тормыш белән,
Таянычы булып халкымның.
Янып торган якты йолдыз кебек,
Балаларга бирә ялкынын.
Еллар, юллар
Кайда гына
Йөретсә дә ул-кызыңны,
Кайнар хисләр белән искә ала...
Онытмаслар,
Мәктәп, юлыңны.
Үзгәрешләр чоры белән яши,
Укытучы эше — яңа табышлар.
Ишетелә мәктәп тирәсендә
Кыңгыраулы,
Якын тавышлар.

Җитмеш еллап мәктәп, кояш булып,
Нурын чәчә —
Нинди горурлык.
Яңавылның төньяк өлешендә
Өч мәктәпкә —
Үзе торырлык.

## Тизрәк чыксаң икән

Өй түрендә гармун уйныйм,
Сагындым, килдем, иркәм.
Көттермәче, нечкә билем,
Тизерәк чыксаң икән.
Көнемне уздыра алмыйм,
Көтеп алам иркәмне.
Сөйләп бирәм бүген кичен
Аңа гашыйк икәнне.

## Урам бәйрәме

Кыңгыраулы атлар чаба
Балалар белән бергә.
Гармун моңнарын таратып,
Мондагы һәрбер өйгә.
Синдә, урам, уйнап үстем,
Гомерем синдә үтә.
Бәйрәмең белән котлыйбыз,
Зур хөрмәт итә-итә.
Зур бәхетне бергә таба
Илдә бергә булганнар.
Урамыңның һәр ягында

Яши дуслар, туганнар,
Данлыклы ветераннар.
Өстәл өсте һәрбер өйдә
Сый-хөрмәт белән тулган.
Уңган кешеләрең мактап,
Яшә син, матур урам.
Яшә син, безнең урам.

## Йөк аты монологы

Тарантаска мине җикмәделәр,
Йөк атлары иде нәселем.
Иртә таңнан кара төнгә кадәр
Йөкләр ташу булды кәсебем.
Инде генә юлга чыгам, дисәм,
Колынчагым кала, кычкырып.
Тәртәләрдән ычкынырга телим —
Нык җиккәннәр, булмый ычкынып.
Кайвакытта явыз машиналар
Бәреп китә минем арбамны.
Сизмәгәндәй, юртам, бара бирәм,
Беркайчан да юлдан язмадым.
Ялгыштырсам әгәр адымымны,
Ялларымнан агып пар чыга.
Акрын атлап, үзем юлны бирәм
Хәлдән таеп килгән юлчыга.
Кеше өчен эшләп шатланганда,
Үз бәхетем калды
Бер читтә.
Шушы гадәтемне ташламадым,
Саклый алдым
Әле ничек тә.



# Безнең буынга

Бала чагың авыр чорда үтте,
Кайгы баскан чакта илемне.
Ач, ялангач, җәяү, ерак йөреп,
Түләп укып, алдык белемне.
Ашаган аш — шул бәрәңге булды,
Күмә идек көлгә, учакка.
Өстәл тулы икмәк хыял гына иде,
Төшкә керми иде ул чакта.
Ә шулай да, укып, ныклы белем алдың,
Чыгып киттең син дә өеңнән.
Яшьлек бит ул үзенекен итә,
Сез киттегез — хыял эзеннән.
Безнең буын — корыч буын, диләр,
Корычтай шул, әйе, түземле.
Бик күп төрле сынауларны үттек,
Исән калдык,
Җиңдек үлемне.

# Мин көтәм

### Җыр

Яныңда вакытта
Белмәдең кадерне,
Ятларга күз салып,
Өздерден бәгырьне.
Ят күзләр алдады,
Әйләнде башларың.
Көтмәдем, белмәдем,
Син мине ташларың.

Мәхәббәт сафлыгын
Белмәдең сакларга,
Гомергә югалтмый,
Бирмичә ятларга.
Уйлатыр, уятыр
Үпкәле сүзләрем.
Мин көтәм, мин беләм
Син мине эзләрең.

# Йөрәкләрдә җыры мәңгелек

**Радик Гәрәев истәлегенә**

Зур талантлар бирә безнең яклар.
Радик булды безгә зур терәк.
Кече яшьтән туды йөрәгендә
«Җырчы булам», — дигән зур теләк.

Шушы теләгенә иреште ул,
Бар дөньяга китте зур даны.
Уртаклаштык шатлыклары белән,
Сәхнәләрдә күреп без аны.

Тыңлый идек аның көр тавышын,
Сүзе бетмәс иде сөйләп тә.
Горурлыгы булып Яңавылның,
Мәңге яшәр безнең йөрәктә.

Сандугачы булды туган якның,
Үзе, җыры — якын һәркемгә.
Радик яши безнең йөрәкләрдә
Үз җырчысы булып мәңгегә.

# Әнием

Туган көнеңдә, әнием,
Телибез саф теләк.
Исән-сау бул, әни,
Син безгә бик кирәк.
Барсына, әнием,
Без сиңа бурычлы.
Мәңгегә түләп тә
Бетә алмам бурычны.

Син безгә зур терәк,
Киңәшчем, сердәшем.
Йөрәгең җылысын
Син безгә өләштең.
Барсына зур рәхмәт,
Әнием, бәгырем.
Сәламәт, шат яшә,
Бергенәм, кадерлем.

# Без бәхетле икән

Без бәхетле икән, туганнарым,
Ярый әле без күп булганбыз,
Сау-сәламәт кенә, җир йөзенә
Җиде бала булып туганбыз.
Туганың күп булу нинди яхшы,
Кайгы-шатлыкларны бүләбез.
Ялгыз булсаң, авыр булыр иде,
Бергә яшәп, дөнья күрәбез.
Ир туганнар — кыз туганга терәк,
Сез бит безгә олы таяныч.
Җиңә алмас идек авырлыкны,
Тормыш булыр иде аяныч.
Тормыш дилгезендә бергә йөзик,
Бергә типсен безнең йөрәкләр.
Гомер буе безне шатландырсын
Уртак уйлар, уртак таләпләр.
Әти-әни ничек кушкан булса,
Тырышабыз шулай яшәргә.
«Алар нәселе» дигән горур исем
Үрнәк булсын, диеп яшьләргә.

# Урлашу

Гаҗәпләнәм әле бу хәлләргә —
Модаларга керде урлашу.
Канга сеңеп, һөнәр булып бара
Шушы эшләр белән булашу.
Хөкүмәттән урлау дәвам итә,
Хәзер урлый күрше — күршесен.

Җай чыкканда, шулай яши бирә,
Күрә алмый кеше бер-берсен.
Ишектәге тотка юкка чыга,
Җилгә «исә» суның краны.
Элгән керләр урынында кипми,
Кемнәр урлый икән боларны?
Туганныкы, әнинеке, дими,
Җае чыкса, җиңел «сугалар».
Өйрәнелә, җаен ала килә,
Баш эшләми, эшли шул куллар.
Бу хәлләргә күнегеп киләбез бит,
Курку, оят, вөҗдан булмагач.
Әйбер урлау хәзер гаҗәпмени —
Кешеләрне кеше урлагач.
Фаҗигале хәлләр арта бара,
Бетмәс, ахры, инде бу гадәт.
Барыбыз да урлап яшик, дисәк,
Ни күрербез икән, җәмәгать?

## Заманы куша шулай

Минем нәни онытым
Бүген атлый башлады.
Күз генә тия күрмәсен,
Имчәген дә ташлады.
Бүгенге тормыш газабын
Онытым тоя бугай.
...Тиз аякка басар өчен
Заманы куша шулай.



## Кыш бабайны көтәбез

Соңлама, Яңа ел,
Көтәбез, безгә кил.
Күчтәнәч, бүләкләр
Өләш син, бүлеп бир.
Җәнлекләр тезелгән
Кыш бабай эзеннән.
Бабакай куймаган
Кар кызын үзеннән.

Ерак юл үткәннәр,
Бик арып беткәннәр.
Яңа ел бәйрәмен
Сагынып көткәннәр.
Сагындык, кил инде,
Кыш бабай, уйнарбыз.
Чыршыны әйләнеп
Биербез, җырларбыз.

## Авырмас идек бер дә

Чана, чаңгыларда шуып,
Яңа эзләр салабыз.
Саф һавада уйнап йөреп,
Иркен сулыш алабыз.
Физкультура дәресләре
Булсалар иде көн дә.
Баһадирдай үсәр идек,
Авырмас идек бер дә.



## Чөгендер басуында

Чөгендере, чөгендере —
Күр әле, ничек булган:
Әкияттәге шалкандай,
Зур үскән, бигрәк уңган.
Яңгыр ява, без төибез
Трактор арбасына.
Гранатадай оча алар

Бер-берсе арасыннан.
Көн буена эшли-эшли,
Ару да онытылды.
Автобуста эссе пардан
Автобус эче тулды.
Өйгә кайткач, эти тирги:
— Нишләдең, син, әй, малай?!
Бер чиста җире калмаган,
Җирдә аунаган бугай.
...Сөйләп биргәч, эти тынды,
Аңладылар мине дә.
Эшләп кайткач, тәмле булды
Бәрәңге дә, ипи дә.

## ЭЧТӘЛЕК

**Чәчмә әсәрләр**

Үзем турында кыскача....3
Язмыш җилләре....4
Күңел күзең күрмәсә....6
«Печать» Рәвил....8

**Шигырьләр**

Әбиемнең йөрәк хатлары....9
Туган як....17
Урал тау бөркете....17
Октябрь бүләк иткән....18
Килмә, картлык....18
Кызлар....19
Чишмәбашым....19
Аккошлар....20
Яңавыл....21
Оныт, диләр....21
Яңа ел, хуш киләсең!....22
Яз килә....22
Матур Бүә буйлары....22
Күңелләрне бәйләп күңелгә....22
Ничек хәлегез?....23
Онытым....24
Син утырткан миләш....24
Онытмадым сине....25
Гөлем....25
Язлар яшьлек хәтерләтә....26
Яшел каен....26
Чишмә....26
Розалия....27
Дан сезгә, апалар....28

Мәктәбем-горурлыгым............................28
Тизрәк чыксаң икән...............................30
Урам бәйрәме.......................................30
Йөк аты монологы..................................31
Безнең буынга.......................................32
Мин көтәм.............................................32
Йөрәкләрдә җыры мәңгелек.........................33
Әнием...................................................33
Без бәхетле икән....................................34
Урлашу.................................................34
Заманы куша шулай.................................35
Кыш бабайны көтәбез...............................36
Авырмас идек бер дә...............................36
Чөгендер басуында..................................36

Китапны басарга әзерләде Инсур Шәңгәрәев

Җыентык авторның үз исәбенә нәшер ителде
Автор спонсорлык ярдәме күрсәткәннәре өчен Яңавыл шәһәре һәм Яңавыл районы хакимияте башлыгы Н.З.Зыязовка, район хакимиятенә, «Башнефть» АНКсы производство-сәүдә фирмасының Яңавыл филиалы директоры Ф.Ә.Исмәгыйловка, «Альбина» ширкәте директоры А.Г.Янчуринага зур рәхмәт белдерә

Сания Вәлиуллина
Язмыш җилләре
Чәчмә әсәрләр. Шигырьләр.
Яңавыл шәһәре, 2000 ел, 40 бит

Яңавыл шәһәр типографиясендә басылды
Заказ 1340. Тиражы 200 экз.
452800, Башкортстан Республикасы, Яңавыл шәһәре,
Азин урамы, 31

Сания Валиуллина
Судьбоносные ветры
Проза. Стихи.
(на татарском языке)

г.Янаул, 2000 г., 40 стр.
Размножено в Янаульской типографии.
Заказ 1340. Тираж 200 экз.
452800, Республика Башкортостан, г.Янаул,
ул. Азина, 31